КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 март г.Казань № 330

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 сентябрь, 739 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 сентябрь, 739 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының беренче абзацында «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.4 пунктның беренче абзацында «күпфатирлы йорт» сүзләреннән соң «(конструктив элементларның физик тузуын бәяләү белән техник тикшерү нәтиҗәләре)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин